**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 декабрь № 979

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү өчен норматив чыгымнар раслау турында» 2014 ел, 26 сентябрь, 683 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү өчен норматив чыгымнар раслау турында» 2014 ел, 26 сентябрь, 683 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм адаптацияләнгән сыек сөт катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүгә хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм адаптацияләнгән сыек сөт катнашмалары белән түләүсез тәэмин итүгә хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативлары

| Табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучылар категориясе | Балаларның яше | Бер елга хезмәт күрсәтүләр саны, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; авырганда табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 942 785 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 3 210 277 | 3 210 277 | 3 210 277 | 3 210 277 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 11 170 105 | 11 170 105 | 11 170 105». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\979.docx